ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

икенче утырыш

09 октябрь 2020 ел　　　　　　№ 11　　　　　　Теләче авылы

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль
районы Теләче авыл җирлеге
Генераль планына үзгәрешләр
кертү проектын раслау турында

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 207 елның 20 ноябрендәге 2019г номерлы карары, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлегенең генераль планы» проектын килештергәндә каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2020 елның 29 сентябрендәге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар бәяләмәсе нигезендә, Теләче муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын расларга, кушымта нигезендә.
2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы　　　　　　Н.Н. Хазипов